ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

# КАРАР

« 01 » июль 2016 ел № 723

**Шәһәр төзелеше өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып, «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибе турында» Башкарма комитетның карары нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Түбәндәгеләрне расларга:

1.1. Җирлекнең генераль планыннан өземтә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (1нче кушымта).

1.2. Инженерлык челтәрләре һәм коммуникацияләр схемасын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (2нче кушымта).

1.3. Күпфатирлы торак йортның беренче катында урнашкан фатирда балкон (лоджия) төзелешен килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (3нче кушымта).

1.4. Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (4нче кушымта).

1.5. тәгәлләнмәгән төзелеш объектын куллануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (5нче кушымта).

1.6. Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (6 нчы кушымта).

1.7. Җир эшләрен житештерүгә ордер бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (7нче кушымта).

1.8. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү буенча (8 нче кушымта).

1.9. Капиталь төзелеш объектларын төзүгә рөхсәт бирү, реконструкцияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (9 нчы кушымта).

1.10. Торак (торак булмаган) бинаны торак булмаган (торак) бинага күчерү (күчерүдән баш тарту) турында хәбәр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (10нчы кушымта).

1.11. Урынны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йорт авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле торак урын дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (11 нче кушымта).

1.12. Торак урынны яңадан урнаштыруга һәм (яисә) яңадан планлаштыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (12 нче кушымта).

1.13. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында булган белешмәләрне күрсәтү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (13 нче кушымта).

1.14. Объектны урнаштыру урынын алдан килештерү турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (14 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерен торуны О.Е. Спичкинга йөкләргә.

Җитәкче И.Ә.Галимуллин